КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 сентябрь г.Казань № 943

Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2023 елга – койка көнгә 825,37 сум күләмендә;

2024 елга – койка көнгә 826,19 сум күләмендә;

2025 елга – койка көнгә 828,88 сум күләмендә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентларын;

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар санын.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 882 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 943 нче
карары белән расланды

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Муниципаль берәмлек исеме | Корректировкалау (төзәтү) коэффициенты күләме | | |
|---|---|---|---|
| | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Зәй муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,502157 | 1,500931 | 1,503861 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Чистай муниципаль районы | 1,455022 | 1,453971 | 1,456925 |
| Яр Чаллы шәһәре | 0,917513 | 0,917421 | 0,919808 |
| Казан шәһәре | 0,917637 | 0,917545 | 0,919932 |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 943 нче
карары белән расланды

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Койкалар саны |
|---|---|
| Азнакай муниципаль районы | 10 |
| Әлмәт муниципаль районы | 10 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 10 |
| Алабуга муниципаль районы | 10 |
| Зәй муниципаль районы | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 10 |
| Лениногорск муниципаль районы | 10 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 10 |
| Чистай муниципаль районы | 10 |
| Яр Чаллы шәһәре | 20 |
| Казан шәһәре | 40 |

_______________________________